**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**12 ноябрь, 2021 ел** **№ 122**

**Биектау муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының даими нигездә муниципаль вазыйфа биләүче затларына хезмәт хакы түләү һәм акчалата бүләкләүләр, муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары, айлык һәм башка өстәмә түләүләр күләмнәрен һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» 2018 елның 25 апрелендәге 220 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Социаль гарантияләрне тәэмин итү, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт хакын түләүне тәртипкә салу һәм камилләштерү, аларның һөнәри хезмәт эшчәнлеген стимуллаштыру максатларында, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 136 статьясы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 22 статьясы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44 статьясы, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 26 статьясы нигезендә, Биектау муниципаль районы Советы,

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Биектау муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының даими нигездә муниципаль вазыйфа биләүче затларына хезмәт хакы түләү һәм акчалата бүләкләүләр, муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары, айлык һәм башка өстәмә түләүләр күләмнәрен һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» 2018 елның 25 апрелендәге 220 номерлы карарына (Советның 23.09.2020 № 4 карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренә аеруча мөһим һәм катлаулы биремнәрне үтәгән өчен премияләр түләүнең күләме һәм аны гамәлгә ашыру тәртибе

1. Аеруча мөһим һәм катлаулы биремнәрне үтәгән өчен премия (алга таба - премия), хезмәткә түләү фондының билгеләнгән күләменнән чыгып, хисап чорында муниципаль хезмәткәр тарафыннан башкарган эш вакытына пропорциональ рәвештә вазыйфаи окладка процент нисбәтендә түләнә.

Премия зат муниципаль хезмәт вазыйфасын били торган җирле үзидарә органы боерыгы (җирле үзидарә органы җитәкчесе күрсәтмәсе (боерыгы)) белән билгеләнә,

анда.

Премия, әлеге бүлектә билгеләнгән очраклардан тыш, хезмәткәрләргә ай саен түләнә.

2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренә аеруча мөһим һәм катлаулы биремнәр башкарган өчен премияләр түләү тиешле җирле үзидарә органы бурычларын һәм функцияләрен үтәүне, вазыйфаи инструкцияне вазыйфаи окладка карата ай саен бер процент күләмендә үтәлүен исәпкә алып, шулай ук әлеге Тәртип нигезендә кабул ителгән тиешле җирле үзидарә органы җитәкчесе карары буенча ел дәвамында эш нәтиҗәләреннән чыгып башкарыла.

3. Тиешле айга эш йомгаклары буенча премия күләме муниципаль хезмәткәрнең яллаучысы вәкиле (эш бирүче) тарафыннан дифференциацияләнгән рәвештә түбәндәгеләрне исәпкә алып билгеләнә:

- җирле үзидарә органына (тармак (функциональ) органына, җирле үзидарә органының структур бүлекчәсенә) йөкләнгән бурычларны, вазыйфаларны үтәүне һәм вәкаләтләрне гамәлгә ашыруны тәэмин итүгә муниципаль хезмәткәрнең керткән персональ өлешен;

- муниципаль хезмәткәр компетенциясенә керүче мәсьәләләрне хәл иткәндә оперативлыгын һәм профессиональлеген;

- муниципаль хезмәткәр тарафыннан тапшырылган биремнәрне үтәүнең, ирешелгән нәтиҗәләре күрсәткечләренең катлаулылыгы, мөһимлеге һәм сыйфаты дәрәҗәсен;

- муниципаль хезмәткәр тарафыннан үз вазыйфаи бурычларын үтәү нәтиҗәләрен.

4. Яллаучы вәкиле (эш бирүче) муниципаль хезмәткәрне премияләмәскә яисә премия күләмен киметергә хокуклы, әгәр муниципаль хезмәткәргә тиешле исәп-хисап чорында дисциплинар җәза бирелгән булса, яки әлеге Нигезләмәнең 3 пунктында санап кителгән күрсәткечләрнең канәгатьләнмәслек нәтиҗәлелеге булган очракта.

5. Аеруча мөһим һәм катлаулы биремнәрне үтәгән өчен муниципаль хезмәткәр премияләре максималь күләм белән чикләнми.»;

2) 15 нче кушымтаны түбәндәге эчтәлекле 7 пункт белән тулыландырырга:

«7) нормалаштырылмаган эш көне шартларында эшләгән өчен айлык компенсация түләве – вазыйфаи окладка карата 55 проценттан артмаган күләмдә.»;

3) 16 нчы кушымтаны түбәндәге эчтәлектә тулыландырырга һәм расларга:

«Нормалаштырылмаган хезмәт көне шартларында эшләгән өчен муниципаль хезмәткәрләргә айлык компенсация түләүләрен билгеләү тәртибе

1. Нормалаштырылмаган хезмәт көне шартларында эшләгән өчен компенсация түләве муниципаль хезмәтнең түбәндәге югары һәм төп вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләргә, шулай ук муниципаль хезмәтнең башка вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләргә исемлек нигезендә башкарылырга тиеш:

Нормалаштырылмаган хезмәт көне булган муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлеге

| N т/б | Вазыйфаның исеме |
|---|---|
| 1. | Башкарма комитет җитәкчесе |
| 2. | Башкарма комитет җитәкчесенең беренче урынбасары |
| 3. | Совет аппараты җитәкчесе |
| 4. | Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары |
| 5. | Башка җирле үзидарә органы җитәкчесе |
| 6. | Башка җирле үзидарә органы җитәкчесенең урынбасары |
| 7. | Башкарма комитет эшләре идарәчесе |
| 8. | Башкарма комитетның мөстәкыйль бүлеге башлыгы (мөдире), башка структур бүлекчәсе (аппараты) җитәкчесе |
| 9. | Советның, Башкарма комитетның мөстәкыйль бүлеге башлыгының урынбасары (мөдире) |
| 10. | Муниципаль район башлыгы ярдәмчесе |
| 11. | Мөстәкыйль сектор мөдире |
| 12. | Советның, Башкарма комитетның һәм башка җирле үзидарә органының баш белгече |
| 13. | Советның, Башкарма комитетның һәм башка җирле үзидарә органының әйдәп баручы белгече |

2. Хезмәт шартнамәсендә хезмәткәргә нормалаштырылмаган эш көне билгеләнү шарты каралырга тиеш.

3. Хезмәткәрне нормалаштырылмаган көн шартларында эшкә җәлеп итү җирле үзидарә органының (эш бирүченең) язмача яки телдән күрсәтмәсе буенча гамәлгә ашырыла.

4. Нормалаштырылмаган көн шартларында компенсация түләүләрен билгеләү хезмәт өчен түләүнең гамәлдәге системасы нигезендә башкарыла торган өстәмә түләүләргә бәйле түгел.

5. Нормалаштырылмаган хезмәт көне шартларында эшләгән өчен айлык компенсация түләве күләме вазыйфаи окладның 100 проценты күләмендә билгеләнә.

6. Өстәмә түләүне исәпләү ай саен башкарыла һәм җирле үзидарә органының айлык акчалата хезмәт хакы белән бергә түләнә.

7. Муниципаль хезмәткәрләргә өстәмә түләү билгеләү турындагы карар муниципаль орган тарафыннан кабул ителә.»;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә һәм үзенең гамәлен 2021 елның 1 ноябреннән барлыкка килгән мөнәсәбәтләргә тарата.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы

Биектау муниципаль районы Советының бюджет, финанс һәм икътисадый сәясәт буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет рәисе урынбасары,
муниципаль район Башлыгы урынбасары Ә.Ш.Шакиров